ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» февраль 2020 г. № 33

**Әгерҗе муниципаль районында җир кишәрлекләренә аренда килешүләре төзү хокукына ачык аукцион үткәрү турында**

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12 статьялары нигезендә, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3.3 статьясындагы 2 пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Әгерҗе муниципаль районының җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына аукционга куела торган җир кишәрлекләре исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. Җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына аукционны оештыру һәм үткәрү буенча аукцион комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

3. Җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына аукционны оештыру һәм үткәрү буенча аукцион комиссиясенә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының әлеге карарныц 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрергә.

4. 3% күләмендә «аукцион адымы» билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына аукцион үткәрү турында хәбәрнамә, электрон формада аукцион үткәрү датасы һәм вакыты турында мәгълүмат, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе рәсми сайтында https://torgi.gov.ru торглар үткәрү турында мәгълүмат, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында, «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәр урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Әгерҗе муниципаль районының җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына электрон формада ачык аукцион үткәрү турында» 23.01.2020 ел, № 20 карары гамәлдән чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әгерҗе муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э. А. Поносовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С.Авдеев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
03 февраль 2020 ел, № 33
карарына 1нче кушымта

# Әгерҗе муниципаль районыныц җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзү хокукына электрон формада аукционга куела торган җир кишәрлекләре исемлеге

| № | Урнашу урыны, мәйданы, җир кишәрлегенең кадастр номеры, аукцион үткәрү өчен нигез, капиталь төзелеш объектының максималь һәм (яки) рөхсәт ителгән минималь рөхсәт ителгән параметрлары, капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруныц (технологик тоташтыру ) техник шартлары һәм аларның гамәлдә булу вакыты, тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен түләү турында мәгълүмат | Рөхсәт ителгән кулланылыш | Арендалау срогы | Башлангыч еллык аренда түләве, сум. | Аукцион адымы (башлангыч бәядән 3%), сум. | Беренчел кертем (башлангыч бәядән 20%), сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1 | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Күләгәш авыл җирлеге,<br>Мәйданы – 92966 кв.м<br>Кадастр номеры - 16:01:010505:20 | Буа урнаштыру өчен | 5 ел | 6507,62 | 195,22 | 1301,52 |
| | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Кадыбаш авыл җирлеге,<br>Мәйданы – 117427 кв.м<br>Кадастр номеры - 16:01:130402:27 | Авыл хуҗалыгы җитештерүләре өчен | 3 ел | 10568,43 | 317,05 | 2113,69 |
| | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Кадыбаш авыл җирлеге,<br>Мәйданы – 35473 кв.м<br>Кадастр номеры - 16:01:130402:26 | Авыл хуҗалыгы җитештерүләре өчен | 3 ел | 3547,3 | 106,41 | 709,46 |
| | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Кичкетаң авыл җирлеге,<br>Мәйданы – 1022302 кв.м<br>Кадастр номеры - 16:01:100509:27 | Авыл хуҗалыгы җитештерүләре өчен | 3 ел | 70232,15 | 2106,96 | 14046,43 |
| | ТР, Әгерҗе муниципаль районы, Красный Бор авылы, М.Горький ур, уч.3а<br>Мәйданы – 615 кв.м<br>Кадастр номеры - 16:01:210106:281 | Шәхси ярдәмче хуҗалык өчен | 20 ел | 14960 | 448,80 | 2992 |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
03 февраль 2020 ел, № 33
карарына 2нче кушымта

**Җир кишәрлекләрен сату буенча аукционнар оештыру һәм үткәрү буенча аукцион комиссиясе составы**

1) Поносов Э.А. – Әгерҗе муниципаль районыныц Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;
2) Андреева И.Е. – Әгерҗе муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе урынбасары;
3) Лукшин П.А. – Әгерҗе муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасыныц контроль һәм исәп бүлеге башлыгы;
4) Рябкова Е.В. – Әгерҗе муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасыныц баш белгече;
5) Короткова Л.В. – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетыныц территориаль үсеш бүлеге баш белгече.